КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 25 сентябрь г.Казань № 743

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына бер кешегә эпидемиягә каршы чаралар үткәрү чыгымнарын раслау турында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 16 мартындагы ТРЗ-19 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына бер кешегә эпидемиягә каршы чаралар үткәрү чыгымнарын расларга.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына бер кешегә эпидемия каршы чаралар үткәрүгә чыгымнарны раслау турында» 2024 ел, 6 сентябрь, 736 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Бу карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 25 сентябрь, 743 нче
карары белән расланды

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына
бер кешегә эпидемиягә каршы чаралар үткәрү
чыгымнары

| Чыгымнар исеме | Бер кешегә чыгымнар, сум | | |
|---|---|---|---|
| | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| Эпидемиягә каршы чаралар үткәрү | 20,49 | 21,31 | 22,16 |

___